Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.12.2022 Менделеевск ш. №809

Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 30 июлендәге 472 номерлы карары белән расланган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 1 бүлегенең 1 пунктындагы 1.1.Абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге нигезләмә муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибен (алга таба - актлар проектлары) билгели һәм эшкуарлык субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.»

1.2.Нигезләмәнең 1 бүлегенең 2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен мәҗбүри таләпләр, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар, түбәндәгеләрдән тыш, Татарстан Республикасы законының тиешле исемлегенә кертелгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларына карата үткәрелергә тиеш:

1) Менделеевск муниципаль районы Советы карарлары проектлары, шулай ук Менделеевск шәһәр Советының җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы карарлары;

2) Менделеевск муниципаль районы Советы карарлары проектлары, шулай ук бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Менделеевск муниципаль районының Менделеевск шәһәр Советы карарлары;

«3) гадәттән тыш хәлләр режимы гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатыннан эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары»;

1.3.1 бүлекнең 4 пунктын үз көчен югалткан дип санарга

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасын рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга (http://mendeleevsk.tatarstan.ru).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад, сәнәгать һәм эшмәкәрлек бүлегенә йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров